**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советы**

Актүбә ш.т.б. № 16 «24» апрель 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының шәһәр тибындагы Актүбә бистәсе Советының 14.12.2017 ел №36 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеген шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативлары турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында (13.12.2018 № 65, 24.05.2019 №22, 20.08.2019 № 36, 16.12.2019 № 53 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексын үтәү йөзеннән, 2012 елның 10 июлендәге 117-ФЗ номерлы «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында Техник регламент» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советы карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының шәһәр тибындагы Актүбә бистәсе Советының 14.12.2017 ел №36 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеген шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативлары турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативларына (13.12.2018 № 65, 24.05.2019 №22, 20.08.2019 № 36, 16.12.2019 № 53 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне 5.2 бүлектә кертергә:

а) 5.2.129 пунктының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ачык һәм ябык типтагы автостоянкалардан күрше объектларга кадәр ераклыкны Шәһәр төзелешенең СП 42.13330.2016 СНиП 2.07.01-89 таләпләренә туры китереп кабул итәргә кирәк. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документларының СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200-03 исәпкә алып башкарылырга тиеш.»;

б) 5.2.176 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Автомобильләргә хезмәт күрсәтү объектларыннан күрше объектларга кадәр ераклыкны Шәһәр төзелешенең СП 42.13330.2016, СНиП 2.07.01.-89 таләпләренә туры китереп кабул итәргә кирәк. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру

һәм төзү янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документларының СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200-03 исәпкә алып башкарылырга тиеш.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогының торак-коммуналь хуҗалыгы, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Рәис Р.А. Галеева